*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2025-2026 нчы уку елы)
**5 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 90 минут**
**Максималь балл – 36**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Парсыз саңгырау тартык авазны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [һ]
   ә) [т]
   б) [й]
   в) [ф]

2. Калын сузык авазлардан гына торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) җиләк
   ә) елан
   б) юкә
   в) дөнья

3. Басымы беренче иҗеккә төшкән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) утырма
   ә) ничек
   б) яшел
   в) урманда

4. ***Тигез*** сүзенең антонимын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) туры
   ә) кыска
   б) кәкре
   в) таза

5. Кушма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) биш-алты
   ә) карабодай
   б) сыйныфташ
   в) кура җиләге

6. Урын-вакыт килешендәге исемне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) мәктәпнең
   ә) мәктәпкә

б) мәктәптән
в) мәктәптә

7. Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**
а) кызыл
ә) кызылрак
б) кып-кызыл
в) кызгылт

8. Сорау җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
а) Алсу мәктәптә укый.
ә) Алсу ничәнче сыйныфта укый?
б) Син дә тырышып укы!
в) Дәрестә сөйләшеп утырмагыз.

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган авазны һәм сүзләрне языгыз. **(4 балл)**

Татар телендә о, ө хәрефләре сүзнең ___________ иҗегендә генә языла. В хәрефе [ ___ ] һәм [w] авазларын белдерә. Күп мәгънәләре сүз туры һәм ___________ мәгънәдә килә ала. ___________ саннарына -нчы/-нче, -ынчы/-енче кушымчасы ялгана.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Сүзләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(4 балл)**

*тень* – ___________ *обезьяна* – ___________
*ласточка* – ___________ *запад* – ___________

2. Мәктәбегез турында 6 җөмлә төзеп языгыз. **(12 балл)**